**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Тарлау торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№ 16 12 ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Тарлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Тарлау торак пунктының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, ПГС салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
Районы Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов